ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от** 06.09.2023 г. Казань **№** 660/2023

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планлы контрольлек (күзәтчелек) чараларын уздырганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләре үрнәкләрен (аларга җаваплар тикшерүдә тотыла торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлекләрен) раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 45/2022 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда планлы контрольлек (күзәтчелек) чараларын уздырганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләре үрнәкләрен (аларга җаваплар тикшерүдә тотыла торган зат тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлекләрен) раслау турында» 2022 елның 28 февралендәге 45/2022 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның «4. Кайнар су белән тәэмин итүне, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын үтәү» бүлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «4. Кайнар су белән тәэмин итү, салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын үтәү | | | | | |
| 4.1 | Мәгълүмат (факт һәм мәгълүмат ачу ысулы) «Федераль җайга салу органы – региональ җайга салу органы – җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – мәгълүмат-аналитика системасы) мәгълүматны төбәк мәгълүмат системасыннан тапшыру юлы белән урнаштырыламы? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларының (алга таба – 108 нче стандартлар) 3 пунктының «а» пунктчасы | | | |
| 4.2 | Мәгълүмат мәгълүмат-аналитика системасында расланган формалар нигезендә урнаштырыламы? | 108 нче стандартларның 7, 8 пунктлары | | | |
| 4.3 | Мәгълүмат «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта бастырыламы (мәгълүмат ачу факты һәм ысулы)? | 108 нче стандартларның 31 пункты, 51 пунктының икенче абзацы һәм 72 пунктының икенче абзацы | | | |
| 4.4 | Мәгълүмат ачу составы һәм тәртибе сакланамы? | 108 нче стандартларның II - IV бүлекләре | | | |
| 4.5 | Җайга салынулы эшчәнлекнең һәр төре буенча һәм һәр үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү системасы, үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасы һәм (яки) үзәкләштерелгән | 108 нче стандартларның 15 пункты | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кайнар су белән тәэмин итү системасы буенча аерым мәгълүмат урнаштырыламы? | | | | |
| 4.6 | Мәгълүмат ачу вакыты (ешлыгы) үтәләме? | 108 нче стандартларның 14, 30-37, 51-58, 72-79 пунктлары | | | |
| 4.7 | Җайга салынулы оешма товарларыннан һәм хезмәтләреннән файдаланучыларның язмача гаризалары нигезендә мәгълүмат ачу тәртибе үтәләме? | 108 нче стандартларның 3 пунктының «в» пунктчасы; | | | »; |

2 нче кушымтаның «4. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын үтәү» бүлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «4. Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар тарафыннан мәгълүматны ачу стандартларын үтәү | | | | | |
| 4.1 | Мәгълүмат (факт һәм мәгълүмат ачу ысулы) «Федераль җайга салу органы – региональ җайга салу органы – җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – мәгълүмат-аналитика системасы) мәгълүматны төбәк мәгълүмат системасыннан тапшыру юлы белән урнаштырыламы? | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 110 номерлы карары белән расланган Җылылык белән тәэмин итүче оешмалар, җылылык челтәре оешмалары һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу органнары тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларының (алга таба – 110 нчы стандартлар) 3 пунктындагы «а» пунктчасы | | | |
| 4.2 | Мәгълүмат мәгълүмат-аналитика системасында расланган формалар | 110 нчы стандартларның 7, 8 пунктлары | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | нигезендә урнаштырыламы? | | | | |
| 4.3 | Мәгълүмат «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта бастырыламы (мәгълүмат ачу факты һәм ысулы)? | 110 нчы стандартларның 31 пунктының икенче абзацы | | | |
| 4.4 | Мәгълүмат ачу составы һәм тәртибе сакланамы? | 10 нчы стандартларның II - III бүлекләре | | | |
| 4.5 | Җайга салынулы эшчәнлекнең һәр төре буенча мәгълүмат урнаштырыламы, алар турында мәгълүмат ачылырга тиешле булган һәм үзара технологик яктан бәйләнмәгән җылылык белән тәэмин итү системасына карата аерым мәгълүмат урнаштырыламы? | 110 нчы стандартларның 16 пункты | | | |
| 4.6 | Мәгълүмат ачу вакыты (ешлыгы) үтәләме? | 110 нчы стандартларның 14, 15, 31- 36, 55-60 пунктлары | | | |
| 4.7 | Җайга салынулы оешма товарларыннан һәм хезмәтләреннән файдаланучыларның язмача гаризалары нигезендә мәгълүмат ачу тәртибе үтәләме? | 110 нчы стандартларның 3 пунктының «в» пунктчасы; 110 нчы стандартларның IV бүлеге | | | »; |

3 нче кушымтаның «4. Региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «4. Региональ операторлар, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторлар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартларын үтәү | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 4.1 | Мәгълүмат (мәгълүматны ачу факты | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | һәм мәгълүмат ачу ысулы) «Федераль җайга салу органы – региональ җайга салу органы – җайга салу субъектлары» бердәм мәгълүмат-аналитика системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – мәгълүмат-аналитика системасы) мәгълүматны төбәк мәгълүмат системасыннан тапшыру юлы белән урнаштырыламы? | гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларының (алга таба – 109 нчы стандартлар) 3 пунктындагы «а» пунктчасы | | | |
| 4.2 | Мәгълүмат мәгълүмат-аналитика системасында расланган формалар нигезендә урнаштырыламы? | 109 нчы стандартларның 7 пункты | | | |
| 4.3 | Мәгълүмат ачу составы һәм тәртибе саклანамы? | 109 нчы стандартларның II бүлеге | | | |
| 4.4 | Мәгълүмат ачу вакыты (ешлыгы) үтәләме? | 109 нчы стандартларның 10, 23- 29 пунктлары | | | |
| 4.5 | Җайга салынулы оешма товарларыннан һәм хезмәтләреннән файдаланучыларның язмача гаризалары нигезендә мәгълүмат ачу тәртибе үтәләме? | 109 нчы стандартларның 3 пунктының «в» пунктчасы. 31 пункты | | | ». |

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина